ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Кутузова ул., дом1,
город Лениногорск, 423250

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

Кутузов урамы, 1нче йорт,
Лениногорск шәһәре, 423250

Тел.: 5-13-80. leninogorsk.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2020 г.Лениногорск № 229

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 18 ноябрендәге 38 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре турында" гы карарына яңа редакциядә үзгәрешләр кертү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 6 статьясы нигезендә Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 18 ноябрендәге 38 номерлы «Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре турында " гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

287 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«287. Җир асты коммуникацияләрендә аварияләр бетерелгәннән соң, юллар, тротуарлар өслекләрен торгызу эшләр тәмамланган мизгелдән соң, 287.1

каралган очраклардан тыш, 10 көнлек сроктан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»; түбәндәге эчтәлекле 287.1 һәм 287.2 пунктлар өстәргә

287.1. Җир эшләре тәмамланганнан соң, эшләр җитештерүче юл өслекләрен торгызу эшләрен башлап җибәрергә тиеш: урамнарның аркылы өзелгән урыннарында - тәүлек дәвамында; машина юлының озынча өзелү урыннары - 5 көн эчендә; җирле юлларны, тротуарларны, газоннарны - 10 көннән дә соңга калмыйча. Аны торгызу алдыннан асфальт өслекнең кырыйлары фреза белән эшкәртелергә тиеш.

287.2.Кышкы чорда, һава шартлары белән һәм температура режимы белән эшләү технологиясен үтәү уңайсыз булуга бәйле рәвештә, җир эшләре тәмамланмаган очракта, эш җитештерүче түбәндәгеләргә бурычлы: җир эшләрен җитештерү зонасында территорияне тәртипкә китерү буенча кирәкле чаралар үткәрергә; юллар (тротуарлар) участокларында, төзекләндерү элементларын тулысынча торгызу мизгеленә кадәр, җир эшләре барышында бозылган җәяүлеләрнең һәм транспортның хәвефсез хәрәкәтен тәэмин итәргә.»

2. . Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Ситдыйковка йөкләргә.

Лениногорск шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г.Хөсәенов